**МИНИСТЕРСТВО**
**ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ**
**И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН**
**ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ**
**ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.09.2014 № 476

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 16 октябрендә теркәлде, № 2451

“Татарстан Республикасында күп балалы
гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты)
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында”
31.07.2012 ел, №612 Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы
боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында
күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты)
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 31.07.2012 ел, №612 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның беренче абзацында “(алга таба – мөрәҗәгать итүче)” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 1.5 пунктны өстәргә:

“1.5. Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны аңлата (27 июль, 2010 ел, №210-ФЗ Федераль Законның 2 статьясындагы 1 пункты). Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы Регламентка №1 кушымтада китерелгән .”;

2 бүлектә:

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (алга таба – таныклык), таныклык дубликты бирү”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту)”;

Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Таныклык (таныклык дубликаты) бирү бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза белән документларны теркәүгә алганнан соң җиде көн эчендә1 хәл ителә”;

Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мөрәҗәгать итүче таныклыкны алу өчен тапшыра:

1. Күп балалы гаилә таныклыгын бирү турында гариза (бу Регламентка №2 кушымта).

2. Никахны теркәү яки өзү турында таныклык күчермәсе (2014 елның 31 декабренә кадәр тапшырыла).

3. 3х4 үлчәмендәге фотосурәт.

4. Иреннән (яки хатыны) түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар) (ирекле рәвештә):

үзләренең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкның булуын;

персональ мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең аның исеменнән эш итүгә вәкаләтен.

Мөрәҗәгать итүче таныклык дубликатын алу өчен тапшыра:

1. Күп балалы гаилә таныклыгы дубликатын бирү турында гариза (бу Регламентка №2 кушымта).

2. 3х4 үлчәмендәге фотосурәт.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспорт (аны алыштыручы документ) күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче, таныклыгын бозу очрагында, таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, бозылган таныклыгын Идарәгә (бүлек) тапшыра.

Документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә алына.

Документлар күчермәләре, закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланмаган очракта, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.

Үзенең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуын раслаучы иреннән (хатыны) алынып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документ Идарә (бүлек) белгече тарафыннан, нотариуста яки Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 185 статьясында күрсәтелгән оешмалар һәм

учреждениеләр тарафыннан расланырга тиеш.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа кушып бирелә торган документлар күчермәләре, паспорт күчермәсен яки аны алыштыручы документ күчермәсен кертеп, закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланырга тиеш.

Дәүләт хезмәте алучының вәкиле дәүләт хезмәтен алучы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документларны өстәмә тапшыра";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлардан торган документлар (ЗАГС органнарында).

2. Никахлашуны, никахны өзүне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлардан торган документлар (ЗАГС органнарында – 2015 елның 1 гыйнварыннан).

Мөрәҗәгать итүче әлеге мәгълүматлардан торган документларны турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә алырга мөмкин. Мөрәҗәгать итүченең югарыда телгә алып үтелгән документларны күрсәтмәве мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тора алмый";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр:

1. Дөрес булмаган (ялган) мәгълүматлардан торган, дәүләт хезмәте алуга хокукны раслаучы документлар тапшыру.

2.Гариза һәм документлар электрон рәвештә җибәрелгән очракта, алар "Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 статьялары таләпләренә туры китереп имзаланмаганда, документларның төп нөсхәләрен яки закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен күрсәтмәү";

3. Электрон рәвештә тапшырылган документлардагы мәгълүматларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән документларга туры килмәве.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән.";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.15 пунктның алтынчы абзацын төшереп калдырырга;

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.16 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Документлар (документлар күчермәләре) электрон рәвештә тапшырылган очракта, алар "Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 статьялары таләпләренә туры китереп имзаланмаганда, таныклык (таныклык дубликаты) тапшыру мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлек) бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән кәгазьдәге документларның документларның төп нөсхәләрен яки

закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен күрсәткәч хәл ителә.”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.16 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны кертеп, МФЦ аша хәл ителми”;

3 бүлектә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Административ процедуралар составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функциядә үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре”;

3.1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү түбәндәге процедураларны үз эченә ала.:”

1)мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

3.2 пунктның беренче абзацына “Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү” дигән сүзләрдән соң “, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан” дигән сүзләр өстәргә”;

3.2.2 пунктның икенче абзацына “дәүләт хезмәте күрсәтү” дигән сүзләрдән соң “һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан” дигән сүзләр өстәргә”;

3.3 пунктта “Таныклык бирү” дигән сүзләрдән соң “(таныклык дубликаты)” дигән сүзләр өстәргә;

3.3.1 пунктчасының икенче абзацында “таныклыкны” дигән сүздән соң “(таныклык дубликатын)” дигән сүзләр өстәргә;

дүртенче абзацка “электрон рәвештә” дигән сүзләрдән соң “, №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 статьялары нигезендә имзаланмаган,” дигән сүзләр өстәргә;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3.3.3 һәм 3.3.4 яңа пунктчаларны өстәргә:

“3.3.3. Идарә (бүлек) белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мәгълүматларны тапшыру турында электрон рәвештә запрослар җибәрә:

таныклык алу өчен мөрәҗәгать иткәндә:

ЗАГС органына 2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларны дәүләт теркәвенә алу турында (2015 елның 1 гыйнварыннан сорала);

җирле үзидарә органына гаилә составы турында;

таныклык дубликаты алу өчен мөрәҗәгать иткәндә:

җирле үзидарә органына гаилә составы турында.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүматлар тапшыру турында запрос.

3.3.4. Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә түбәндәге мәгълүматларны ала:

ЗАГС органыннан 2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларны дәүләт теркәвенә алу турында, никахлашуны, никахны өзүне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар;

Идарәче компаниядән гаилә составы турында.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүматлар алу.";

3.3.3 пунктчасын 3.3.5 пунктчасы дип исәпләргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3.5. Идарә (бүлек) белгече бу Регламентның 3.3.3 һәм 3.3.4 пунктларында күрсәтелгән, алынган мәгълүматлар һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Идарә (бүлек) белгече бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булмаганда, түбәндәгеләрне хәл итә:

таныклык бланкын рәсмиләштерә;

таныклык бланкын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Гариза һәм документлар электрон рәвештә алынган очракта таныклык бланкы мөрәҗәгать итүче бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны күрсәткәч рәсмиләштерелә.

Идарә (бүлек) белгече бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булганда, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасында (хат белән, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша) күрсәтелгән таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында карарны җиткерә.

Бу пунктчада күрсәтелә торган процедуралар гариза теркәлгәннән соң ике көн эчендә, әмма җиде көннән дә соңга калмыйча хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә таныклык бирүдән баш тарту турында җиткерү, таныклык бланкын рәсмиләштерү.".

3.3.4 пунктчасын 3.3.6 пунктчасы итеп исәпләргә;

3.3.5 пунктчасын 3.3.7 пунктчасы итеп исәпләргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3.7. Идарә (бүлек) белгече:

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат белән, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша) таныклык (таныклык дубликаты) тапшыру турында карар җиткерә;

мөрәҗәгать итүченең личное делосын рәсмиләштерә (барлык документларны

аерым папкага туплый);

таныклыклар (таныклыклар дубликатлары) бирү кенәгәсенә №4 кушымта нигезендә язып куя;

Мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) тапшыра.

Бу пунктчаның 2,3 абзацларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедура төгәлләгәннән соң бер көн эчендә, бу пунктчаның 4,5 абзацларында күрсәтелгән процедуралар – мөрәҗәгать итүче әзер таныклык (таныклык дубликаты) алу өчен мөрәҗәгать иткән көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында җиткерү, мөрәҗәгать итүченең личное делосын, таныклык (таныклык дубликаты) рәсмиләштерү.

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.4 пунктны өстәргә:

“3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү МФЦ аша хәл ителми.”;

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.4. Гражданнар, аларны берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге нигезендә хәл ителә.”;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе”;

5.3. пунктның икенче абзацында “почта аша,” дигән сүзләрдән соң “МФЦ аша” дигән сүзләр өстәргә;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.9. пунктны өстәргә:

“5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.”;

Регламентка № 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №1 кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

______________________________

(муниципаль район (шәһәр округы)
Идарәсенә (бүлек)

**ГАРИЗА № _____**

“____” _________________ 20 __ ел

Мин, ____________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме – тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яшим: ____________________________________

( индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы)

Шәхесне раслаучы документ төре, ______________________________________________

Сериясе____ №____ бирелүе______________________________________________________

(кайчан, кем тарафыннан)

Күп балалы гаилә ______________________________ бирүегезне сорыйм.

таныклык (таныклык дубликаты)

Гаилә составы:

| Ф.И.О. | Туу датасы | Яшәү урыны буенча теркәлү адресы |
|---|---|---|
| | | |

Гаиләм составына керүче балаларның тулысынча дәүләт тәэминатында тормаганлыкларын, опекага тапшырылмаганлыкларын, үземнең ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителмәгәнлегемне раслыйм.

Түбәндәге документларны кушып бирәм:

1.______________________________________________________________________

2.______________________________________________________________________

3.______________________________________________________________________

Тапшырылган документларның чынлыгын һәм бәян ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон нигезендә, персональ мәгълүматларны мәгълүмат алмашу системасында җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган рәвештә, саклауга һәм өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм ________

_________________________________________________________________________ ,

(дәүләт хезмәте алучының, балигъ булмаган балаларының, шулай ук, гариза дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә торган зат тарафыннан тапшырылса, мөрәҗәгать итүченең ФИО күрсәтелә)

_________________________________________________________________________ ,

бу Гаризада күрсәтелгән ____________________________________ ,

(мөрәҗәгать итүче имзасы)

Мөрәҗәгать итүче:

_________________________________________ _________ “___”_____20__ ел.

(Дәүләт хезмәте алучының яки билгеләнгән (имза)
тәртиптә расланган ышанычнамә нигезендә дәүләт
хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып
эш итүче затның ФИО)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга риза _______________________________

(язмача, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша)

“___” ________ 20___ ел. Имза __________

Гариза һәм документлар кабул ителде ___ 20__ ел _____ ____________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

____________________________________________________________

(ерту өчен сызык)

Расписка-белдерү кәгазе

Документлар саны ____ берәмл. ______ битләрдә

Документларны кабул итте _____________ _____________ ________ 20 ___ ел.

(имза) (тулы имза) (дата)”;

Регламентка №4 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №4 кушымта


**Таныклыклар (таныклыклар дубликатлары) бирү кенәгәсе**

| п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Өй адресы | Таныклык (таныклык дубликаты) сериясе һәм номеры | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү датасы | Таныклык (таныклык дубликаты) алучы имзасы | Искәр түләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Регламентка №5 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №5 кушымта

**Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы**




"Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерже муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85551) 2-10-86 2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш., К.Маркс ур., 8 й., Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85592) 7-25-10 7-14-25 | 423300, Азнакай, Болгар ур., 9 й. Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84344) 2-73-68 2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б., Ленин ур., 8 й. Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85552) 3-11-46 3-12-81 | 423740, Актаныш ав., Юбилей ур., 45 й. Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84341) 2-41-40 2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б., Казаков ур., 8 й. Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84346) 2-08-90 2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9 й. Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8553) 32-45-50 | 423452, Әлмәт ш., 8 март ур., 21а й. Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84376) 2-11-84 2-10-81 | 422350, Апас ав., Шоссе ур., 5 й. Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84366) 3-13-53 3-13-33 | 422000, Арча ш., Банк ур., 6в й. Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84369) 2-16-60 2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав., Октябрь ур., 9 й. Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85569) 5-10-50 5-66-81 | 423930, Баулы ш., Җиңү мәйданы, 4 й. usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84368) 2-44-78 | 422250, Балтач ав., Һ.Такташ ур., 3а й. Usz.Baltasi@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85594)<br>4-20-05<br>4-26-64 | 423230, Бөгелмә ш.,<br>Совет ур., 56 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-35-35<br>3-17-03<br>3-55-29 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43 | 422700, Биектау ст. т.юлчылар б.,<br>Профсоюз ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав.,<br>Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-51-55<br>7-87-86 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 5 й.<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-10-64<br>3-43-59 | 423520, Зәй ш.,<br>Крупская ур., 6 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>5-79-90 | 422540, Зеленодол ш.,<br>Ленин ур., 25 й.<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>К.Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85563) 3-12-36 | 422190, Мамадыш ш., Совет ур., 10 й. Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85549) 2-23-00 | 423650, Менделеев ш., Бурмистров ур., 7а й. Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85555) 3-26-59 3-19-77 3-14-52 | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 80 й. Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85556) 2-57-37 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе | (8552) 34-48-48 58-71-52 | 423805, Чаллы ш., Х.Туфан проспекты, 23 й. Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районында социаль яклау идарәсе | (8555) 45-39-20 45-43-86 45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш., Тынычлык проспекты, 60 й. usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84348) 2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й. Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84345) 2-06-62 2-06-55 2-39-88 | 423040, Нурлат ш., Мәктәп ур., 8 й. Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84367) 3-06-68 3-06-72 | 422770, Питрәч ав., Совет ур., 20 й. Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84361) 2-11-57 2-39-62 | 422650, Балык бистәсе ав., Завод ур., 6а й. Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84362) 2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б., Тукай ур., 87 й. Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85559) 2-45-72 2-49-87 | 423350, Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й. Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84347) 3-08-81 | 422840, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 13 й. |

| | | |
|---|---|---|
| | 3-00-00<br>3-08-98 | Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57 | 423807, Чаллы ш.,<br>М.Җәлил проспекты, 46 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав.,<br>Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Гагарин ур., 7 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-11-50 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкий ур., 45 й.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91<br>2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б.,<br>Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан. ш. Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036 Казан ш., Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан. ш. Вахитов районы социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420043 Казан ш., Вишневский ур., 10 й.<br>Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан. ш. Киров районы социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102 Казан ш., Г.Баруди ур., 5 й.<br>Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан. ш. Мәскәү районы социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095 Казан ш., Блюхер ур., 81а й<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан. ш. Яңа Савин районы социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420044 Казан ш., Ямашев пр., 37 й<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан. ш. Идел буе районы социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420059 Казан ш., Р. Зорге ур., 39 й.<br>Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан. ш. Совет районы социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420037 Казан ш., Г.Кутуй ур., 33 й.<br>Usz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларына функциональ аудит бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |

".

**Министр** **А.Р.Шәфигуллин**